| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.06.2024 г. Казань № 1440

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
12.09.2019 № 251 боерыгына
Кушымта №1гә үзгәреш кертү
турында

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендәге сугыш ветераннары өчен госпитальләрдә гражданнарның льготалы категорияләрен медицина белән тәэмин итүне оештыру максатларында, боерык бирәм:

«Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләре сугышлар ветераннары өчен госпитальләрендә гражданнарның льготалы категорияләренә медицина ярдәмен оештыру турында» 12.02.2019 № 251 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының боерыгына кушымта № 1гә (Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 30.03.2020 № 566, 28.03.2023 № 590 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Категория исеме» баганасында пункт 2:

2.2 пунктчасында «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренә)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге 2.3 и 2.4 пунктчалары белән тулыландырырга:

«2.3) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында 2014 елның 11 маеннан башлап хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан затлар;

2.4) 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, шулай ук 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән

бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) затлар;»;

«Категория исеме» баганасында пункт 3:

8 пунктчасында «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренә)» сүзләрен өстәргә)»;

Түбәндәге эчтәлектә 9 һәм 10 пунктчалары белән тулыландырырга:

«9) Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә Донецк Халык Республикасы Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы халык милициясе, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы хәрби формированиеләре һәм органнары составында 2014 елның 11 маеннан башлап хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан затлар, күрсәтелгән хәрби хәрәкәтләрдә катнашу сәбәпле алган яралану, контузия, гариплек яки авыру нәтиҗәсендә инвалид булганнар;

10) 2022 елның 24 февраленнән Украина, Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территорияләрендә, шулай ук 2022 елның 30 сентябреннән Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция барышында Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешмалар белән контракт төзегән (башка хокук мөнәсәбәтләре булган) затлар, күрсәтелгән бурычларны үтәүдә ярдәм итү бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алган яралану, контузия, гариплек яки авыру нәтиҗәсендә инвалид булганнар.».

Министр вазифаларын башкаручы,
Министрның беренче урынбасары Ә.Р.Абашев